**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «26» маеннан № 34-276

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм аның белән идарә итү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 30 маендагы 26-161 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2008 елның 30 маендагы 26-161 номерлы карары белән (2008 елның 30 маендагы 44-267 номерлы, 2011 елның 14 сентябрендәге 8-59 номерлы, 2016 елның 28 июнендәге 15-59 номерлы карарлар редакциясендә) расланган «Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм аның белән идарә итү тәртибе турында» нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 1.3 пунктының 20 пунктчасын «һәм мәдәнияты)» сүзләреннән соң «Россия Федерациясе халыклары (алга таба - мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәният һәйкәлләре)» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http//novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгы В. М. Козлов